ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК

ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.01.2021 г.Лениногорск № 1

Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2017 елның 22 мартындагы 4 номерлы карары белән расланган агач һәм куаклар кисүгә, кронлаштыруга яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенең, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең уртак коллегия беркетмәсен үтәү йөзеннән, Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2017 елның 22 мартындагы 4 номерлы карары белән расланган агач һәм куаклар кисүгә, кронлаштыруга яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге өстәмәне кертергә:

2.6 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында мәгълүматлар-Россия ФСХ. Мәгълүматлар авария хәлләренә бәйле очраклар өчен бирелми.»;

2.8 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 5 подпункт белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу.»;

3.4.1 пунктын сүзләр белән тулыландырырга:

«һәм законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурычлар булу (булмау) турында белешмәләр.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында һәм гражданнарны күзәтү өчен мөмкин булган мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Җитәкче Р.Р.Сытдиков

Л.М. Галимова
5-44-72